*Школьная газета «Тамчы»*
Выпускается с октября 2008 года

Издаётся один раз в месяц

**Шеф редактор**: учитель татарского языка и литературы Шайдуллина Ландыш Камиловна

**Номер подготовили** Альмеева Резеда, Шайдуллина Айгуль, ученицы 10 классов

Мнение автора может не совпадать с мнением редколлегии.

**Приём материала** (статей, рассказов, стихов, рисунков и др.) **и предложений** осуществляется через членов редколлегии или шеф-редактора (307 каб).

# Әлфинур Флеровна

МАХСУС САН МАХСУС САН МАХСУС САН



**Яшь чагында нинди идегез, Әлфинур апа? Берәр хатирәгезне сөйләгез әле...**

Яшь чакта мин бик актив кеше идем. Мәктәп елларында мәктәптән кайтмадык. Нинди түгәрәк бар, барысына да йөрергә тырыштым. Хәтта мандолинада да уйнап карадым. Әртист булып китеп булмаса да, бераз шыңгырдатып булды үзе тагын.

Әртист дигәннән, бар иде андый хыял. Әле дә төрле бәйгеләр булып тора. Рәхәтләнеп катнашам мин ул концертларда. Дөресен әйткәндә, никтер комедия күңелемә хуш килә. Тамашачыларның йөзләрендә елмаю күрсәм, сәхнәдә уйнавы да рәхәт. Әртистләнеп йөрү сәләтен Ходай үзе бераз биргәндер дип уйлыйм.

**Мәктәптәге иң яратмаган дәресләрегез нинди иде?**

Сызым (черчение) дәресен бик яратып бетерми идем. Ник дисәң, сыза белмәдем шуны. Аны инде безнең чорда өйрәтеп тә житкерә алмаганнардыр инде. Укытучы артыннан укытучы алышынып торды. Эзлеклелек булмады. Үземне гаепле итмим әле, балалар да шулай бит: “Мы не виноваты”, - диләр.

**Киләчәктә 5нче сыйныф укучылары нинди булыр, ничек укыр?**

Киләчәкне уйларга куркам мин нишләптер. Әллә инде яшь үзен сиздерә. Ничектер бүгенге мәгариф системасына ияреп бара алмыйм әле мин. Узган еллар белән чагыштырганда, 5 нче сыйныф укучыларының белемнәре саерак, тәртипләрен дә үзгәртергә кирәктер дип уйлыйм. Ә бит башлангыч сыйныф укытучылары бик актив, белемле, позитив безнең мәктәптә. Ә менә ата-аналарга тәрбия җитеп бетми. Ата-аналар белән мәктәп арасында ниндидер бер киртә бар. Алып атарга иде шул киртәне.

МИНЕМ ӘБИЕМ ИҢ ЯХШЫСЫ

БӘЙГЕ КЫСАЛАРЫНДА

Өлкәннәр көне Өлкәннәр көне Өлкәннәр көне

# Ак яулыклы әбием



Өебезнең яме булып, безнең белән әниемнең әнисе яши. Ак яулыклы ак әби ул безнең. Яхшы киңәшләр биреп, матур теләкләр теләп яши әби. Без аның хәер-догасында яшибез.

Иртән мәктәпкә киткәндә озатып кала, кайтканда каршы ала. Әбием олы яшьтә булса да, һаман тәмле ризыклар белән безне шатландырып, сыйлап тора. Әбием кул эшләрен дә яратып эшли. Гомер буе ул авыл кешеләренә матур күлмәкләр тегеп кидергән. Аның сырган юрганнары кемнәрнең генә төн йокысын җылытмаган. Әбием бу эшләрне үзлегеннән өйрәнгән.

Инде сиксән яшькә җитсә дә, һаман үзенә бер шөгыль табып тора. Хәзер ул үзенең яшь чагындагы һөнәренә кайтты — чигү чигә башлады. Аның чиккән мендәр тышлары төрле күргәзмәләрдә катнашты. Әбием шуның өстенә дини дә. Матур итеп Коръән укый, мөнәҗәтләр әйтә.

Әбиемә озын гомер телим. Безне шатландырып, озын-озак гомер кичерсен.

**Галләмова Ильвина, 9 а сыйныфы укучысы**







# Тамчы

Икенче санлы Җәлил мәктәбе газетасы,
**Сентябрь, 2017 ел**

# Яңа уку елына иң изге теләкләр

Кадерле укучылар. Хөрмәтле ата-аналар, хезмәттәшләр.

Сезнең барыгызны да 1 нче сентябрь — Белем бәйрәме белән тәбрик итәм. Бәйрәм уңаеннан минем иң зур хөрмәт сүзләрен укытучыларга, белем йортының барлык хезмәткәрләренә җиткерәсем килә. Хезмәтегез өчен рәхмәт Сезгә. Сез барыбыз өчен игътибарлылык һәм таләпчәнлек үрнәге булып торасыз.

Узган уку елын мәктәбебезне 33 укучы тәмамланды. Бүген алар бөтенесе дә югары уку йортларында белем ала башладылар.

Белем учагы район һәм республика күләмендәге олимпиадалардагы призлы урыннар буенча алдынгы позициядә булды. Быелгы уку елында да сынатмабыз, нәтиҗәләрне тагын да яхшыртырбыз дип ышанам

Куандырганы шул: безнең мәктәбебез районда иң зур, иң яхшы мәктәпләрнең берсе. Яңа уку елына әзерлек барышында да сынатмадык. Район мәктәпләре арасында үткәрелгән бәйгедә без 2 урынны яуладык.

Бүген мәктәп бусагасыннан атлап кергән һәр укучыга уңышлар телисем килә.

Мәктәп директоры буларак, шуны ышандыра алам: бу уку елы кызыклы һәм онытылмас сәхифәләргә бай булачак. Без, хөрмәтле укы-



тучыларыбыз белән берлектә, белем алу процессын гади, тик шул ук вакытта мавыктыргыч, кызыклы итәргә тырышырбыз. Сезнең белән бергәләшеп фән дөньясы серләрен ачарбыз, көчебезне, осталыгыбызны эшкә җигәрбез, сабыр гына сезгә юл күрсәтербез. Шушы белем йорты, аның туган диварлары безгә ныклы таяныч булыр, көч бирерләр.

Кадерле укучылар, сез яңа 2017-2018 нче уку елына аяк басасыз. Бу уку елы сезнең өчен яңа ачышлар, файдалы белемнәр, гүзәл кичерешләр, матур хатирәләр елы булсын иде.

9, 11 нче сыйныф укучылары алда торган имтиханнарга әзерләнә башлыйлар. Онытмагыз, сезнең киләчәгегез үзегезнең кулыгызда.



Киләчәк җиңүләрегезнең нигезен ныклы итеп салыгыз. Белем алыгыз, иң-иңнәр арасында иң яхшысы булырга омтылыгыз. Белемле булсагыз, сезнең алда барлык ишекләр ачыла. Бу уку елында сез киләчәгегез билгеләргә, олы тормыш юлына сукмакны табарга, имтиханнарны уңышлы тапшырып чыгарга тиешсез. Тырышыгыз — сез моны булдырачаксыз. Уңышлар сезгә!

**Р.К.Сәетгәрәева, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры**

# Чулпан Камиловна

## НӘРСӘ УЛ БӘХЕТ?

**Чулпан Камил кызы Шәйдуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы — мәктәбебезнең иң сабыр һәм тырыш мөгаллимнәрнең берсе. Активлыгына таң калырсың: укучылары татар теле һәм әдәбияты олимпиадаларында җиңә, «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә катнаша.**
**9 нчы сентябрь көнне туган көне булды Чулпан апаның. Бу форсаттан «Тамчы» редколлегиясе ашыгыч интервью алырга йөгерде! Рәхим итеп укыгыз!**




МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

НАГРАЖДАЕТСЯ

ШАЙДУЛЛИНА
ЧУЛПАН
КАМИЛОВНА,
учитель татарского языка и литературы МБОУ «Джалильская средняя общеобразовательная школа №2» Сармановского муниципального района, за подготовку призера в республиканской олимпиаде по татарской литературе

Министр Э.Н. Фаттахов

11 февраля 2013 года

Махсус сан Махсус сан Махсус сан

**- Укытучы юлы ничек башланып китте? Династиягездән кем иң зур йогынты ясады сезгә?**

Безнең нәселебездә укытучылар күп. Әнинең энесе Хатыйп абый һәм сеңлесе Хәнифә апа озак еллар шушы өлкәдә хезмәт куйдылар. Хатыйп абый Миннегулов әле бүген дә студентларга белем бирә, борынгы татар әдәбияты фәненнән кызыклы лекцияләр укый. Озак еллар укытучы булып эшләгән шушы остазлар бу һөнәргә карата кызыксыну уяттылар, шушы һөнәрне сайлауда этәргеч булдылар. Бүгенге көндә тынгысыз жанлы сеңлем Ландыш Камил кызы белән бер коллективта эшләвем белән горурланам, чөнки ирешкән уңышларымда аның өлеше шактый күп.

**- Татар әдәбиятымы яки татар теленме? Нигә? Нәрсә укыту күңеллерәк?**

Рус балаларына татар телен өйрәтү бик җиңелдән түгел, чөнки ул алар өчен чит тел булып санала. Шулай да аларга бу телне өйрәтүгә кызыксыну уятырга тырышам. Эшемнең нәтиҗәсе дә бар. Ике ел рәттән минем укучым Фролов Александр рус балалары арасында татар теленнән олимпиаданың республика турында призер булды

**- Татар телен саклар өчен, безгә нинди өч гамәлне ясарга кирәк?**

Татар телен белү һәм саклау өчен татар телендә аралашу, сөйләшү мөмкинлекләрен күбәйтергә, татарча нәфис фильмнар күрсәтергә, татарча җырлар тыңлатырга һәм татар теленең матур, моңлы, җанга газиз тел булуын аңлатырга, белдертергә кирәк, дип уйлыйм.

**- Нәрсә ул бәхет? Ә укытучы бәхете?**

Минемчә, бәхет—ул гаиләң булу, сәламәт булып яшәү һәм яраткан эшең булу. Әти-әниең,туганнарың булу да тормышта бик кирәк. Укытучының бәхете - укучыларның рәхмәтле булып кала белүләрендә. Озак еллар үтсә дә, син укыткан укучылар сине онытмыйча, күңелләрендә сакласалар, очрашканда хәлләрне сорашсалар, шул хисләр яшәргә өмет һәм күңелдә шатлык уяталар. Бу, күпмедер дәрәҗәдә, хезмәтеңә бәя дә булып тора.

**- Яшьлектән бәрәр хатирәне сөйләгез әле...**

Университетны тәмамлангач, Иске Кәшер мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгәндә булган бер вакыйга исемдә калган. Изге Вәли көнендә укучылар хатлар яздылар. Миңа да бер мәхәббәт хаты укырга туры килде. Билгеле, укучы егет үз исемен язмаган иде. Шулай да ул егетнең кем булуын уйлап йөрдем, чөнки чын күңелдән җылы хисләр белән саф татарча язылган хат күңелемдә зур кызыксыну уятты.

**- Сезнең белән гомер буена яшәргә стимул бирә торган сүз, девиз, материаль әйбер - нәрсә ул?**

Киләчәккә өмет, ышаныч белән карап, эшләгән эшләреннең нәтиҗәле булуына сөенә белү кирәк. Син укыткан укучыларның үз юлларын дөрес табулары да яшәргә һәм эшләргә зур көч биреп торалар.

**- Быелгы мәктәп үзгәрешләренә сез ничек карыйсыз? Бәлки, идеяларыгыз бардыр?**

Мәктәптәге үзгәрешләргә мөнәсәбәтем яхшы. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр белән янәшә атлаучы мәктәбем алга таба да зур уңышларга ирешер, алдынгы урыннарда булыр дигән теләктә калам.

***Син укыткан укучыларның үз юлларын дөрес табулары да яшәргә һәм эшләргә зур көч биреп торалар.***

**Чулпан Камил кызы! Туган көнегез белән! Сезгә бәхет-шатлык, сәламәтлек, зур уңышлар телибез.**



МАХСУС САН МАХСУС САН МАХСУС САН

# Әлфинур Флеровна

## Киләчәкне уйларга куркам

**Рус һәм татар теле укытучысы һөнәрен бер кеше үти аламы? «Әлбәттә, әйе!», - дип җавап кайтара безгә Әлфинур Флеровна Гарифуллина. 13 сентябрь көнне дөньяга килгән яраткан укытучыбызның вакыты ай-һай бик аз! Әлфинур Гарифуллина редколлегия әгъзалары сорауларына вакыт табып, чын күңелдән җавап бирде. Туган көнегез белән!**

**Укытучы юлын ничек башладыгыз, Әлфинур Флеровна?**

Минем уйлавымча, мин укытучы булырга тиеш идем. Безнең нәселдә үзләрен әлеге һөнәргә багышлаган кешеләр шактый. Ә инде минем өчен үрнәк кеше – ул Салих бабам, Мөнүр абыйларым. Әле дә хәтеремдә, кечкенәдән сеңлем белән укытучылы уйный идек. Иң кызыгы күрше кызларын укыту иде. Кемдер курчаклы уйный, ә мин шулай

## МӘКТӘПТӘН КАЙТМАДЫК

укытучы булып уйнадым. Менә шулай, уйнаган хуш килде, укытучы булдым.

**Бу уку елы яңалыклары ошыймы сезгә?**

Әлеге уку елында, дөресен генә әйткәндә, мин әле бер яңалык та күрмим. Әлегә кәгазь боткасында кайныйбыз.

**Киләчәктә нинди яңалыкларны күрәсегез килә?**

Киләчәк турында уйлаганда, элек-электән үк яхшылыкка өметләнгәннәр бит. Чернышевскины гына алыйк. Ашты бит язучының хыяллары тормышка! Киләчәк – ул барлык кешеләргә дә яшәү өчен бер рәхәтлектер дип уйлыйм мин. Ә инде иң мөһиме: тынычлык.

**Сез, татар һәм рус теле укытучысы булarak, ике телдә саф сөйләшергә тырышасыз. Ә хәзерге кешеләрне татар һәм рус телендә сөйләшергә ничек өйрәтергә?**

Телләр белгән илләр гизгән. Ике телне камил өйрәнүем өчен мин үземнең әниемә рәхмәтле. Мин бит авыл кызы. Ә авылда, без үскән чорда русча сөйләшү, гомумән, юк иде дисәм дә була. Әнием яшь чагында Тагил якларына чыгып киткән. 16 яшьлек авыл кызы, рус телен ипи-тозлык кына белүе аркасында, бик интеккән зур шәһәрдә. Үзе шушы телдә камил сөйләшергә өйрәнгәч, балаларыма ике телне дә кирәкле дәрәҗәдә өйрәтермен, дип сүз биргән. Ә инде мәктәптә рус теле укытучым Миннур Якуповна рус телен тел итеп өйрәнүгә зур этәргеч бирде. Телне өйрәнү, телгә өйрәтү, минемчә, гаиләдән килә. Бүгенге көндә татар телен, үзләренең туган телләрен, өйрәнәсе килмәгән кешеләрне күреп, йөрәк әрни.



**Сезнең камил укучыгыз бармы? Укучы андый булырга тиешме?**

Әлбәттә, һәр укучы камил булырга тиеш. Белемне барлык укучыларга да тигез өләшәбез бит.

**Яшегезгә караганда сез бик яшь күренәсез. Матурлык сере нидә?**

Гел мәктәптә, балалар арасында йөреп, яшь кешеләр белән аралашып яшь калмасаң, дөрес булмас иде ул. Һәрвакыт позитив булырга кирәк.

(ДӘВАМЫ 4НЧЕ БИТТӘ)